ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

28 август 2026 ел N 29

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советының 2022 елның 14 октябрендәге 62 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 2 статьясын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2 статья. Депутат вәкаләтләре чоры

1. Депутат вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Советының тулы хокуклы составта беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.

2. Депутат вәкаләтләре чоры “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының “Иске Гришкино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнә;

1.2 3 статьяның 1 пунктында нигезләмәне үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип тану;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан ителү;

5) аңа карата судның гаепләү хөкеменең законлы көченә керүе;

6) даими яшәү урынына Россия Федерациясеннән читкә китү;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит дәүләт гражданлыгы йә яшәүгә рөхсәте яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булу;

8) җирле үзидарәнең тиешле органы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

9) хәрби хезмәткә чакырылу яисә аны алмаштыручы альтернатив граждан хезмәтенә юллама;

10) чит ил агенты статусын алу;

11) әлеге Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән башка очраклар.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//prav.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru Иске Гришкино авыл җирлегенең "Норматив документлар" бүлегендә урнаштырырга.

Иске Гришкино авыл җирлеге Советы
рәисе К.И.Алексеев